**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЕРХНЕПИНЯЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ ПӘНӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 7** **15.03.2022г**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм срокларын раслау турында»**

«Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүлә органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары идар органнарына, җирле үзидарә органнарына, бюджет керемнәренең ба администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнарына беркетүгә һә Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминият фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеге раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендә 1569 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Росси Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә органнарын җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюдже керемнәренең баш администраторын беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъект бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирл бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга гомум таләпләрнең 10 пункт нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль район Югары Пәнәче авыл җирлеге башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлег бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр керт тәртибен һәм срокларын кушымта буенча расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
3. Карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль район рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикас хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **М. Х. Туктаров**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Югары Пәнәче авыл җирлеге
башкарма комитетының
15.03.2022 ел 7 номерлы
карары белән расланган.

## Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе һәм сроклары

1. Әлеге тәртип «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторын беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга гомуми таләпләрнең 10 пункт нигезендә эшләнгән һәм ул ул Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә (алга таба – исемлек, баш администратор) үзгәрешләр кертү механизмын һәм срокларын билгели.

Баш администраторларның составы һәм (яки) функцияләре үзгәргәндә, шулай ук Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге бюджеты керемнәре классификациясе кодларын билгеләү һәм бирү принциплары үзгәргәндә, исемлеккә, шулай ук Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге бюджеты керемнәре классификациясе кодларының баш администраторларына беркетелгән составка үзгәрешләр Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы финанс-бюджет палатасы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 09 декабрендәге 30 номерлы карарына үзгәрешләр кертми генә кертелә.

Исемлеккә үзгәрешләр, бюджет керемнәре классификациясенең төп администраторларына беркетелгән кодлар составында үзгәреш өлешендә, федераль һәм региональ законнарга үзгәреш кертелгән саен кертелә.